*Единство в многообразии*

# Ф И К Е Р

**Орган Казахстанского конгресса татар и башкир**
**№3 (116) 2018 ел**

**Газета «Фикер» выходила в 1905-1907 гг. при участии Габдуллы Тукая. С 1993 г. выходит в г. Алматы: с 2000 г. под названием «Фикер-Өмет», с 2013 г.«Фикер».**

==========================================================================

## ТАТАР ТЕЛЕ

*Вы, прадеды наши в недоле*
*мукою запудривших лик,*
*на мельницах русских смололи*
*заезжий татарский язык.*
*Ярослав Смеляков*

Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да
Гасырларның афәт җиле,
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине.
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй, мөкатдәс Тукай теле.

Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле!

Кабатланмас үткәннәрең-
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле, дуслык теле.

*Наҗар Нәҗми*



**НАЖАР НӘҖМИ (1918-1999)**

Шагыйрь, драматург, публицист Нажар Нәҗми (Хәбибнаҗар Нәҗметдин улы Нәҗметдинов) 1918 елның 5 февралендә хәзерге Башкортостан Республикасы Дүртөйле районы Миңеште авылында дөньяга килгән. Авылдагы җидееллык мәктәпне тәмамлап, Уфада рабфакта укыган. 1938 елда Башкорт дәүләт педагогика институтының тел һәм әдәбият факультетына укырга кергән. 1941-1945 елларда –Бөек Ватан сугышында катнашкан. Сугыш беткәч, бүленгән укуын дәвам итеп, институтны тәмамлаган. «Совет Башкортстаны» газетының, «Әдәби Башкортостан» журналының, «Һәнәк» журналының редакцияләрендә эшләгән; Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрының директоры, Башкортостан Язучылар берлегенең рәисе булган.

Нажар Нәҗми Башкортостанның Верховный Советына депутат булып сайланган, РСФСР ның һәм Башкортостанның Язучылар берлеге әгъзасы, язучылар съездларының делегаты булган. «Капка ачучы малай», «Шагыйрь һәм патша», «Урал» һәм башка поэмаларның, күп санлы шигырьләрнең, җырларның авторы.

Нажар Нәҗми – РСФСР ның Максим Горький исемендәге, Башкортостанның Салават Юлаев исемендәге, Татарстанның Гаяз Исхакый исемендәге премияләр лауреаты, Башкортостанның халык шагыйре. Ул Октябрь Революциясе ордены белән, ике мәртәбә Бөек Ватан сугышы ордены белән, ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрак ордены белән, Кызыл Йолдыз ордены белән, Хөрмәт ордены белән, күп санлы медальләр белән бүләкләнгән.

Аның исемен мәңгеләштерү максатында Нажар Нәҗми яшәгән йортка мемориаль такта куелган, Миңеште авылында музей ачылган, Нажар Нәҗми исеме Дүртөйле шәһәрендәге гимназиягә, скверга һәм бер урамга бирелгән. Шул скверда Нажар Нәҗмигә һәйкәл куелган. Атаклы әдип үзенең васыяте нигезендә туган авылында җирләнгән. Миңеште авылына килеп керә торган урында, тау башында, шагыйрь җырга салган Ак чишмәгә якын гына җирдә Нажар Нәҗминең кабере һәм аңа багышланган мемориаль комплекс урнашкан.



**Мемориаль комплекс**



## АВЫЛДАШЫМ НАҖАР АГАЙ

Башкортостанның Дүртөйле районында минем күңелемдә, йөрәк түрендә һәрчак саклана торган, мәңгегә онытылмас ике авыл бар. Берсе –Казаклар авылы- туган авылым, җиде яшемә кадәр минем таныган-белгән бердәнбер авылым иде ул. Ничәмә буын ата-бабаларым җирләнгән, кендек каным тамган изге туфрак ул. Икенчесе-Миңеште авылы, шул авылның гади генә мәктәбе миңа олы юлны ачты, еракларда бик сагынып шул авылга кайтып йөрдем. Шушы авылның зираты әткәм-әнкәм өчен дә, абыем һәм апам өчен дә мәңгелек йорт булды...

1944 ел иде. Әткәем, сугышта бер аягын калдырып, Казакларга кайтып төште. Аны Миңеште авылына эшкә юнәлткәч, гаиләбез белән шунда күчеп килдек, шунда мин беренче сыйныфны тәмамладым. Икенче елда- күптән бирле зарыгып көткән Бөек Җиңү, аннан соң исән-сау, гарипләнгән- гарипләнмәгән солдатлар да кайта башлады. Бик матур, якты кояшлы, җылы җәйге көннәрнең берсендә: «Югары оч Рәдифнең абыйсы кайта икән», -дигән хәбәр таралды. Район үзәге Дүртөйледән телефон аша хәбәр иткәннәр икән (Шул елларда бөтен авылга бер генә телефон инде ул, колхоз идарәсендәге телефон). Малай-шалай югары очка йөгердек, Рәдиф безнең яшьләрдәге малай бит, бер мәктәптә укып йөрибез.

Кайтучы солдатны каршылаучылар анда байтак икән. Озак та үтмәде, кап-кара, ялтыравык, озын, без гомергә дә күрмәгән, күз алдына китерәлмәслек матур машина килеп туктады. Машинадан бик күркәм, ыспай киемле хәрби абый килеп чыкты да, олылар белән исәнләшә башлады. Аннары машина эченнән бик зур гармун (анысы- аккордеон дип атала икән) чыгарды да, Рәдифкә асып куйды. Без, малайлар, Рәдиф өчен шатландык микән, әллә бигрәк тә көнләштек микән, хәзер аңлавы да кыен инде. Менә шушы абыйның исеме Нажар икән, ул Рәдифнең әнкәсенең бертуган энесе булып чыкты.

Соңыннан атаклы шагыйрь Нажар Нәҗми булып танылачак кешене беренче күрүем иде бу. Әлбәттә, Нажар агай белән очрашулар бер генә булмады, ул авылга кайткан саен без аны күрә идек. Табигый ки, аның белән минем арада бернинди дә якын танышлык булуы мөмкин түгел иде. Ул танылган әдип, ә мин аның бер авылдаш малае гына, аңа әңгәмәдәш булырлык түгел инде. Очрашканда «Исәнмесез, Нажар агай», дисең дә, аның җавабына куанып, гадилегенә сокланып, үз юлың белән китәсең. Ләкин безнең авылдан да шундый данлыклы кеше чыккан булуы бер миңа гына түгел, башка авылдашларга да борын чөяргә мөмкинчелек бирә иде инде.

Нажар агай белән соңгы тапкыр очрашуым 1997 елда Казан шәһәрендә булды. Казакъстан татарлары делегациясе составында Бөтендөнья татар конгрессының чираттагы съездына килгән идем. Иртән делегатларны автобусларда съезд мәҗлесенә алып китәргә тиешләр. Кунакханәнең ишегалдына чыксам, анда төрле яклардан килгән делегатлар тулып тора. Монда Башкортстаннан килгән делегатлар да булырга тиеш иде. Берәр танышымны очратырга өметләнеп, мин якташларымны эзләп киттем. Карасам, шунда Нажар агай басып тора ләбаса! Мин малай чакта бик озын булып күренгән агай шактый кечерәйгән, тик



**Агыйдел буенда (Миңеште авылы)**

чәчләре генә элеккечә таралып, арыслан ялларына охшап тора. Дөрес, хәзер аппак инде ул чәчләр, ләкин Нажар агай икәнен күрсәтеп тора бит! Бардым янына, исәнләштем дә, үземнең дә Миңештедән икәнемне әйттем. Ул танымыйча:
-Бәй, син кем малае?-дип сорады.
-Хайруллинның кече малае,-дидем мин.
-Аның кече малае читтә иде бугай бит.
-Әйе, мин шул читтәге малае инде.

Моннан соң без бераз сөйләшеп тордык. Ул минем кайда яшәвем, нинди эштә эшләвем турында сораштырды, мин Башкортстандагы хәлләр белән кызыксындым.

Икенче көнне без тагын очраштык. Кунакханәнең ишегалдындагы делегатлар арасында Нажар агайның аппак башы әллә кайдан күренеп тора. Ул үзе төрле якка борыла, нидер, әллә кемнедерме эзли сыман. Янына барып, исәнләштем. Ул мине эзли икән, миңа бүләк итеп үзенең китабын әзерләп куйган. «Татар каны» дип аталган шушы китапка ул: «Грифкә, Казакларда туган Миңеште егетенә. 29.VIII.97.» дип язып, имзасын куйган.

Казаннан Алматыга күтәреп кайткан бүләкләрнең иң кадерлесе шушы кечкенә китап булды. 60 яшеңә җитеп, Нажар агайның үзеннән «егет» атагын ал әле син! Алматыга кайткач, шушы бүләк тәэсире белән мин Нажар агайга түбәндәге шигыремне язым җибәрдем.

***Ерактан хат***

*Китап бүләк иттең, язып миңа:*
*«Миңештедә үскән егеткә».*
*(Егетлеген, ярый, егет булыйм,*
*Тик чәчләргә күптән бәс төшкән).*

*Шигъри юлларыңнан, Нажар агай,*
*Күзләремне аера алмадым.*
*Никадәр хис,*
*Нинди тойгылар бар,*
*Нинди уйга мине салмадың!*

*Олы бөтен бәхеттер бу җирдә*
*Шундый шагыйрь була алуы.*
*Үзең генә беләсеңдер, моңа*
*Күпме кирәк йөрәк януы.*

*Янсын синең йөрәк озак еллар,*
*Шулай янсын, сүнмәс, пыскымас.*
*Дөрләп янсын бу арусыз йөрәк,*
*Бу тынгысыз йөрәк һич тынмас.*

*Шатланырбыз яңа шигыреңә,*
*Киләчәктә синең әсәрләр*
*Безгә тагын тирән тәэсир ясар,*
*Күңел түрләрендә яшәрләр.*

*Чыгышымны берәү сорап калса,*
*Мин җаваптан читкә кагылмам.*
*Бераз масаеп та әйтеп бирәм:*
*Мин- Миңеште дигән авылдан,*
*Нажар Нәҗми туган авылдан.*

Нажар агай бүләк иткән китап бүген дә өстәлем өстендә. Туган халкым язмышы турында уйланганда, татар телен җәберсетү очраклары турында сүз чыкканда Нажар агайның шигырьләре көч биреп тора сыман. Аның «Татар теле» исемле шигырен генә алып карагыз! Рус шагыйре Я. Смеляков тарих өлкәсендә надан булуы аркасындамы, яисә шовинизм чире тәэсиренә бирелепме,

белмим, ләкин татар телен кимсеткән шигъри юлларын язган. Аның фикеренчә, татар теле читтән килгән бер килмешәк (заезжий) имеш, аны да руслар тегермәндә тартып бетергәннәр икән (смололи). Нажар Нәҗми моңа нигезле җавап биргән: татар теле моңлы да, ачык йөзле дә, гайрәтле дә, акыллы да, чукындырганда да чукынмаган тел бит ул! Аны хәтта фашист тегермәне дә тарталмаган, ул төрмәләрдә дә бирешмәгән, ул үз илендә, ул килмешәк түгел!

Китаптагы һәрбер шигырь Нажар Нәҗминең татар халкы өчен борчылуын, кайгыруын, аның язмышы өчен җаны әрнеп торуын ачык күрсәтә. «Мин үземә һәйкәл куялмадым» дип башланган шигырендә ул һәр халыкның да үз җирендә үзе хуҗа булырга, үз телен сакларга хокуклы икәнен раслый:

*Кем атар соң минем исемемне*
*Туган җирдә, туган телемдә?*
*Әгәр дә ул өйдәш булып калса*
*Үз өендә, туган өендә.*
*Мин үземә һәйкәл куялмадым-*
*Балкырдаен җырлар нурыннан.*
*Туган телсез мин юк! Ә юкларга*
*Кайда нинди һәйкәл куелган?*

«Татар акылы төштән соң» дигән әйтемгә ишарәләп, «Татар акылы» исемле шигырендә Нажар Нәҗми татар халкының язмышы мәсьәләсенә тагын әйләнеп кайта.

*Ерткыч талаган кош йоны*
*Сибелгән кебек җиргә,*
*Таланып, татар, таралдың,*
*Сибелдең илдән-илгә.*
*Дәүләтсез дә, гаскәрсез дә*
*Калдың син, бөек милләт.*
*... Җәбердән һәм хурлыклардан*
*Йөрәктә канлы яра.*
*...Татар акылы төштән соң,*
*Кайчан төш җитәр икән?*

Татар халкының көчле рухын, батырлыгын шагыйрь «Татар барда хәтәр бар» дигән мәкаль белән бәйли («Бар!» дигән шигырь). Чынлап та, татар барда хәтәр булу белән бергә, хәтәр булган җирдә, әлбәттә, татарга юлыгасың.

*Гасырлардан, иске заманннардан*
*Тутыкмаган иске хәбәр бар.*
*Кем әйткәндер, кайчан әйтелгәндер:*
*«Татар барда,-диеп,- хәтәр бар».*
*...Кая бакма- хәтәр җирдә татар,*
*Үлемнәрнең сыртын сындырып,*
*Утлардан да, Моабитлардан да*
*Кем соң чыкты моңлы җыр булып?*
*Палач балтасына башны тотып,*
*Көлеп үлгән икән татарлар,*
*Дошман өчен, сатлык җаннар өчен*
*Татар барда, чынлап, хәтәр бар...*
*Бар!*

Бу юлларда халкыбызның горурлыгы булган Муса Җәлил һәм аның иптәшләренә ишарә ясала. Башка бер шигырендә («Кичер мине») Нажар Нәҗми турыдан-туры Муса Җәлилгә мөрәҗәгать итә. Бөек Ватан сугышы язмышы белән - Демблин, Радом, Берлин юлларыннан Муса Җәлил дә, соңрак Нажар Нәҗми дә үткәннәр.

*...Әйтерсең лә, дошманнарны куып,*
*Мин тик сине эзләп барганмын.*
*...Бу хәтерләү нигә кирәк хәзер-*
*Синең даның шуңа калганмы?!*
*Палачларга сине бирмәс идем,*
*Кичер мине- соңлап барганмын!*

1552 ел фаҗигасы татар халкының күңелендә мәңгелек яра булып бүген дә саклана. Табигый ки, Татарстанда «Хәтер көне» игълан ителде: октябрь аеның башында үткәрелә торган бу көнне без, татарлар, туган җирен явыз баскынчылардан яклап, җанын фида кылган ерак бабаларыбызны искә алабыз. Нажар Нәҗминең «Хәтер көне» исемле шигыре шул һәлакәтне искә алырга, тарихыңны онытмаска чакыра.

*...Күпме гасыр халык йөрәгеннән,*
*Милли яралардан кан тама.*
*Татар өчен җәбер, мыскыл нәрсә,*
*Рус өчен бәйрәм, тантана.*
*...Кайтты бүген хәтер көне генә,*
*Ә хәтердә коллык, күпме кан.*
*Киләчәгең булмаячак, татар,*
*Үткәнеңне әгәр онытсаң.*

Үзенең башка әсәрләрендә дә шагыйрь халкыңның тарихын, аның үткәннәрен белергә кирәк,-дигән фикерне алга сөрә; тарихыңны белмәүне милләтсез, туган халыксыз яшәүгә тиңли:

*Кайберәүләр әйтә: үткәннәргә*
*Керү нигә-буш һәм вакытсыз.*
*Аларча бит яшәп була хәтта*
*Милләтсез һәм туган халыксыз* («Татар каны» поэмасыннан).

Гомумән, рус дәүләте белән татар халкының үзара мөнәсәбәтләре, татар халкының шушы дәүләт тарафыннан җәберсетелүе Наҗар Нәҗминең байтак шигырьләрендә ачыклана.

*Булды заман-урыс «акылын»да*
*Тыелды бит сабан туйларың да,*-
дип ачына шагыйрь («Мөстәкыйльлек»).

«Күз яше фонтаны» исемле шигырьдә – шагыйрьнең Кырымда Бакчасарайны тамаша итеп йөргәндә алынган тәэсирләре нигезендә туган фикерләре. Сарайның борынгы нурлы, балкып торган чагын искә алып, Наҗар Нәҗми аның бүгенге мыскыллы, хәрабә хәлен тасвирлый. Бакчасарайдагы фонтан образы аша татар халкының тарихына, мәдәниятенә мыскыллап карауны ачып күрсәтә.

*Монда бүген урыс хакимлеге*
*Аңкып тора һәрбер диварда.*
*Әби патша белән Потемкинның*
*Зина кылып яткан диван да*
*Төп комарткы булып урын алган...*
*...Фонтан, фонтан!*
*Һаман Кырым өчен*
*Тартыш бара ике арада.*
*Алар өчен татар бар ни, юк ни...*
*Күз яшьләре һаман тамалар.*
*Фонтан елый...*

Балет остасы, та тар баласы мәшһүр Рудольф Нуриевның язмышы, аның азатлыкка омтылуы турында уйлануларын Наҗар Нәҗми түбәндәге юллар белән тасвирлый:

*...Күнеккән бит урыс татарны тик*
*Күрергә гел иблис сынында.*
*Ә ул «иблис» япа-ялгыз көе*
*Урыс богавыннан ычкынып,*
*Йөремәде читтә хәер сорап,*
*Париж урамында ышкылып.*
*Ә очты ул талант канатында*
*Дөнья сәхнәләрен бер итеп,*
*Хөр булмаган халкы өчен янып,*
*Үз язмышыпн, җанын хөр итеп.*
(«Талант канатында» исемле шигырьдән)

Рудольф Нуриевның Парижда урыс зиратында җирләнүе уңаеннан Наҗар Нәҗми:

*Татаргамы соң ул аерым зират?...*
*Шулдыр инде язмыш ырыскал:*
*Хәтта теге дөньяда да татар*
*Үлеп котыла алмый урыстан,*- ди.

Россия дәүләтенең колониаль сәясәтенә каршы чыга торган фикерләр шагыйрьнең байтак шигырьләрендә урын алган. Мисал өчен, «Нигә шулай?» дип аталган шигырен Наҗар Нәҗми: «Минем туган илем булган кебек, урысның да туган иле бар», -дип башлый. Россия киң дә, зур да. Шулай булгач, нигә урыс «Ата-баба җирен, йорт, илен» ташлап әллә кайларга китә? –дип сорау куя Наҗар Нәҗми.

*...Кем икмәген ашар өчен китә,*
*Үзен-үзе итеп мәсхәрә?*
*... Нигә кирәк бутау кеше йортын,*
*Үзеңнеке итеп исәпләп?*
*...Әй китәләр...Азат тормыш эзләп,*
*Байлык эзләп әллә кайларга.*
*Азатлыкны да бит, байлыкны да*
*Үз илеңдә кирәк яуларга.*

«Мичкә» исемле шигырьдә Наҗар Нәҗми «Төньяк Кавказ дары мичкәсе өстендә тора» дигән, киң таралган раслауны уртага сала да:

*Ул мичкәне кем китергән,*
*Кем куйган соң монда аны?*
*Ермоловлар!...Ә ул кемнең,*
*Кайсы халык генералы?*
*...Ул мичкә тора Казанда*
*(Ул дүрт гасыр инде тора).*
*Мичкә шартламасын өчен*
*Хуҗа төрле хәйлә кора,*-дип йомгаклый.

«Бүгенге тәфтиләүләр» (Тәфтиләү-урыс дәүләте хезмәтендә булып, башкорт восстаниесен бастыруда катнашкан татар мирзасы Котлы-Мөхәммәт Тевкелев фамилиясенең яңгыравы) исемле шигырьдә Наҗар Нәҗми:

*Бүген дә рус үз тәргән*
*Тәфтиләүләрдә күрә.*
*Төрле-төрле хәйлә корып,*
*Милләт көрәген томтырып,*
*Милләтне көрәттерә,*- дип, үз милләтенең мәнфәгатьләренә каршы чыгучылардан көлә. Яңа заман Россиянең



**Нажар Нәҗми һәм Роберт Миңнуллин**

колониаль сәясетенә чик куяр, дигән өмет белән шагыйрь 1994 елда түбәндәге дүртьюллыкны язган:

*Көч булганда акыл кирәкми, дип*
*Әйткән урыс- чыккан сугышка.*
*Килде заман. Көч куллану бетте!*
*Нишләргә соң хәзер урыска?*

Әлбәттә, бер кечкенә мәкаләдә Нажар Нәҗми иҗатына, хәтта аның иҗатының бер генә тармагына да һәрьяклап анализ ясау мөмкин түгел. Безнең алга андый максат куелмаган да иде. Бүген без милләттәшләребезгә, аларның Идел-Урал төбәгеннән читтә гомер сөрүчеләренә тагын бер мәртәбә халкыбызның бөек әдипләре турында мәгълүмат бирүне урынлы дип санадык. Моның өчен Нажар Нәҗминең йөз еллык юбилее да кирәкле форсат булды. Милли үзаңыбызны югалтмыйк, дисәк, танылган шәхесләрбезне дә, тарихыбызны да белергә тиешбез бит, шул белемне балаларыбызга һәм оныкларыбызга да җиткерү- монысы да безнең бурыч.

***Гриф Хәйруллин, Алматы***

***Фикер № 3, 2018 ел***



## РУДОЛЬФ НУРИЕВ (1938-1993)

«Очып йөрүче татар» дип бөтен дөньяга танылган бөек биюче Рудольф Хәмит улы Нуриевка (Нуреевка) быел 80 яшь тулган булыр иде.

Киләчәк балет остасының әтисе Хәмит Нуриев Уфа шәһәреннән ерак түгел урнашкан Әсән авылында туган. Кызыл Армиядә хезмәт иткән, Бөек Ватан сугышы ветераны: Мәскәүдән башлап Берлингәчә барып җиткән кеше. Әнисе Фәридә Аглиуловна Казан губернасында дөньяга килгән.

Хәмит Нуриевның хәрби хезмәте Казанда булган, аннары аның хезмәте Маньчжуриядә дәвам иткән. Фәридә ханым ире янына барырга юлга чыккач, шул поездда Рудольф дөньяга килгән. Бу хәл поезд Иркутски шәһәреннән ерак түгел урында булганлыктан, баланың туган җирен «Иркутски шәһәре» дип куйганнар. Соңрак Хәмит Нуриевны Мәскәүгә күчергәннәр. 1941 елда, Бөек Ватан сугышы башлангач, аның гаиләсен Уфага эвакуациягә җибәргәннәр. Шулай итеп, өч яше тулыр-тулмастан, кечкенә Рудольф өченче регионда яши башлаган. Шул елларда Советлар Союзында яшәгән бик күп кордашлары кебек үк, гаиләдә дүртенче бала булган бу малай ачлыкны-ялангачлыкны тулысынча татыган.

Рудольф кечкенәдән бию белән кызыксынган. Ул Уфадагы балалар фольклор ансамблендә биеп йөргән, аннары Мәдәният йортында биегән.

1955 елда Р.Нуриев Ленинградтагы хореография училищесына укырга кергән. Уку елларында Рудольфка укытучысы А.Пушкин өендә яшәргә туры килә, чөнки интернатта сабакташлары аны «авыл малае» дип мыскыл итә торган булганнар.

Училищены 1958 елда тәмамлап, ул Киров исемендәге опера һәм балет театрына эшкә кабул ителгән. Кыска гына вакыт арасында яшь биюче үзен танытып өлгерә. Шуңа күрә 1961 елда Киров театрының Көнбатыш Европага гастрольгә чыгучы труппасы составына Рудольф та кертелә. Ул Парижда труппа белән бергә була, ләкин Лондонга барырга аңа рөхсәт ителми. Рудольф Нуриев СССРга кайтудан баш тарта һәм Парижда кала. Моның өчен аны СССРда «хыянәтче» дип игълан итәләр.

Европада биюченең таланты тулы ачыла, ул байтак классик балетларда төп рольләрне бии, тамашачыларның мәхәббәтен яулап ала. 15 елдан артык ул Лондондагы Король балетының йолдызы, озак вакытлар Вена труппасының премьеры була. Ул чынлап та бөтен көчен биреп, барлык талантын җигеп, ару-талуны да белмәстән, ашкынып эшли. Һәрбер елда 200 гә якын чыгышлар ясый ул, ә бер 1975 ел дәвамында аның чыгышлары саны 300 гә җитә. Рудольф Нуриев спектакльләрдә катнаша, киноларга төшә, телевидениедә чыгыш ясый, балетлар куя. 1964 елда Вена операсында ул «Аккош күле» балетын куя, шунда үзе төп партияне бии. Балет тамашачыларга шулкадәр көчле тәэсир итә ки, алкышлар озак туктамый, сәхнәнең пәрдәсен 80 нән артык мәртәбә күтәрергә-төшерергә туры килә. Бу бөтен дөньяда бер театраль рекорд була.

Атаклы балерина Майя Плисецкая Рудольф Нуриевның биюе турында: «Ул тулысынча хәрәкәт белән яна иде, әгәр хәрәкәтне термометр белән үлчәп булса,- дип, юкка гына әйтмәгәндер.- Биюнең пафосы аңарда, үзенең корбаннарын эшафотта яндыра торган ут булып ялкынланды. Аның сәләте могҗизалы сыйфатка ия иде, бу сыйфат йөрәкләрне җылыта да ала, кешедәге явызлык һәм акылсызлыкны яндыра да ала».



*Хәмит Нуриев гаиләсе белән*

1983-1989 елларда Рудольф Нуреев Париж операсынында балет труппасының директоры була, яшь артистларны үз канаты астына ала. Соңгы елларда ул дирижер хезмәтенә күчә.

1987 елда аңа СССР га кыска гына вакытка кайту рөхсәт ителә, авыру әнисе белән күрешергә өлгерә ул. Әнисен үз янына алып килеп, аның тыныч картлыгын тәэмин итү хыялы гамәлгә ашмый кала. 1992 елда аны Казанга чакыралар, ул монда «Ромео һәм Джульетта», «Щелкунчик» балетларына дирижер була. Бу аның туган якларын соңгы күрүе була...

Рудольф Нуриев Париждан ерак түгел Сент-Женевьев-де-Буа дигән урында рус каберлегендә җирләнгән.

Аның кайбер шәхси әйберләре-костюмнары, документлары һ.б.ш. Франциядә Милли Китапханәдә һәм Карнавал музеенда саклана. 2013 елда Мулендагы (Франция) Сәхнә костюмнары милли үзәгендә «Нуриев коллекциясе» исемендәге бүлек ачылган.. Париж операсының бер залына Рудольф Нуриев исеме бирелгән.

Аның хөрмәтенә мемориаль такталар Париждагы, Лондондагы, Нью-Йорттагы йортларга куелган. Сан-Марино дәүләтендә аңа багышланган почта маркалары чыгарылган.

Уфадагы Башкорт хореография көллиятенә Рудольф Нуриев исеме бирелгән. Башкорт опера һәм балет театрында Нуриев музее ачылган. Уфадагы бер урам Рудольф Нуриев исемен йөртә. Аңа багышланган барельеф һәм мемориаль такта да куелган Уфада. Рудольф Нуриевка мемориаль такта Иркутски шәһәрендә дә бар.

Казанда Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрында һәр ел саен классик бию буенча Рудольф Нуриев исемендәге Халыкара фестиваль үткәрелә. Мондый Халыкара фестиваль Уфада Башкорт опера һәм балет театрында да ел саен үтә.

Уфада Рудольф Нуриев хакында «Визит» дип аталган сәнгатьле фильм төшерелгән. Мәскәүдә Зур театрда «Нуреев» исемле балет спектакле куелды.

Үзенең автобиографиясендә Рудольф Нуриев шулай дип язган иде: «Минем әнием борынгы гүзәл Казан шәһәрендә туган. Без мөселманнар. Әтием Башкортостан башкаласы Уфа янындагы кечкенә бер авылда туган. Шулай итеп, ике яктан да безнең туган-тумачалар - шушы татарлар һәм башкортлар...Минем өчен татар булуым, ә рус булмавым нәрсә икәнен төгәл генә аныклый алмыйм, тик үземдә мин бу аерманы тоеп торам. Безнең татар каны ничектер тизрәк ага һәм һәрвакыт кайнап китәргә әзер».

Менә шундый кайнап торган гомер кичерде бу даһи татар баласы...

***Алматы***



## «Я ОГЛЯНУЛАСЬ ПОСМОТРЕТЬ....»

Раиса Гарифовна Бикмухаметова– Почетный Гражданин Северо-Казахстанской области, Заслуженный работник культуры Республики Татарстан, председатель правления татаро-башкирского центра «Дуслык» в 1989 - 2012 годы, Почетный журналист Казахстана. Проработав 40 лет на телевидении г.Петропавловска, она создавала богатейший документальный архив региона, в том числе – телеочерки «Земляки». И вот в 2017 году-в год 70-летнего юбилея, ее коллеги решили дополнить этот цикл фильмом об авторе. Мы отправились по памятным местам Раисы Мамлютовой- Бикмухаметовой.

Она родилась в Петропавловске в послевоенное время в семье железнодорожников. Папа – Гарифулла Мамлютов, фронтовик, участник двух войн, работал в линейном отделе милиции и в локомотивном депо. В 1953 году построил дом в рабочем поселке по адресу - улица Белинского, 7.

*«В моей судьбе ты стала главной-родная улица моя! ...Я с грустью спела эти строки из песни, когда мы подъехали к месту, где когда-то стоял папин дом.... Здесь прошло наше детство. Мой папа – прямой потомок основателя Мамлютки, который переселившись в 1786 году из Казанской губернии по старому Сибирскому тракту, заложил дом у озера, недалеко от Петропавлоска, затем там разрослось поселение, которое назвали Мамлютка. А мама была дочерью казака, который служил в царском войске на Горькой линии – в станице Становое. В начале мы жили в деревянном бараке у самой железной дороги, потом построили дом, в котором в отличии от барачной комнаты, было все необходимое для большой семьи, огород, полисадник со цветами и деревьями. К сожалению, теперь ничего не осталось, снесли новые хозяева».*

В семье Мамлютовых - было пятеро детей, когда в их дом пришла беда. Мама –Бибикамал добрая и хорошая хояйка, любящая, очень гостеприимная и щедрая, очень рано ушла из жизни, когда Раисе было всего 15 лет.*«У мамы было тяжелое детство. Ее отца Сибагатуллу Аитова вместе со всеми казаками станицы Становое в 1923 году за службу в царском войске, арестовали и расстреляли... Все семьи лишились кормильцев, причем это - и русские, и татары, и казахи. А через три года у Бибикамал умерла мама , девочка осталась круглой сиротой и воспитывалась у родственников в Мамлютке. Там она и встретила бравого солдата Гарифуллу Мамлютова, когда он вернулся в 1938 году с русско-японской войны, получив ранение на озере Хасан. Они поженились и переехали в Петропавловск, где у них родился первенец – сын Равиль, а в январе 1942 г. папа ушел на фронт и вернулся после Победы. У меня самые добрые воспоминания о нашем детстве, любовь и достаток в доме, дети хорошо учатся. Мама долго болела, лечение не помогло, и она ушла из жизни в декабре 1962 года. Ей было всего 42 года, а мне -15. Это - страшное испытание, потрясение... Вот здесь, у ворот нашего дома собрались соседи, родственники чтобы проводить маму. Не могу без слез вспоминать тот день»*

Папа остался один. Пятеро детей - старший – в армии, Раиса училась в 8 классе, сестра – в 6, брат- во втором, самому младшему – четыре года. Соседи советовали отдать их в детский дом, но он решил все делать сам, готовил детям

кушать, печку топил и успевал на работу бежать. *« Я, как старшая помогала ему во всем, особенно с маленьким, с утра-в садик, разные домашние дела-после школы. И примерно, год спустся, папа привел в дом женщину и сказал:«Это Мария Сергеевна, она будет жить с нами и будет вашей мамой». Я очень испугалась, мачеха! Никогда в жизни она не сделала ничего плохого, всегда доброжелательная и спокойная. Потом, когда я уехала учиться в Алма-Ату, а сестра – в Россию, она выучила двух младших мальчишек и помогала устроить их жизни. Светлая память нашей бабе Маше! Так стали мы ее называть, когда у них с папой появилсиь внуки»*.

Училась Рая в 31 железнодорожной школе и, по словам нашей героини, среди учителей было много ленинградцев и москвичей.. Именно в эту школу мы сейчас и отправляемся.*« Вот здесь мы познавали жизненные ценности. В нашей школе была какая-то светлая аура. Позже мы узнали, что в годы войны здесь учился Володя Шаталов, их семья эвакуировалась в Петропавловск, а после полета в космос, он приезжал и школе было присвоено имя Владимира Шаталова, а в центре города участановлен бюст Космонавту. Большинство наших преподавателей, это – эвакуированная или ссыльная интеллигенция. Их отличала высокая культура, манера общения с детьми. Нам повезло с учительницей русского языка и литературы Тамарой Георгиевной Максимовой-киевлянкой. Она знакомила нас с новыми литературными изданиями, поэзией шестидесятников – Е.Евтушенко, Р.Рождественским, А.Вознесенским. Заметив в учениках какой-то литературный дар, давала задание написать стихи. И я начала пробовать. Здесь, в этой школе мы получили хорошие знания, а уроки Тамары Георгиевны позволили мне заняться поэзией и публиковаться в местной прессе».*

После школы Раиса отправилась учиться на факультет журналистики в КазГУ. Студенческие годы были связаны с поэзией, публикациями репортажей для местных газет. В стенах Альма-матер студенты научились снимать на кинокамеру пейзажи в горах Алатау, интервью , небольшие зарисовки.*« Мы часто ходили в горы на лыжах. Наш преподаватель Марат Кирибаевич Барманкулов предлагал нам взять с собой ручные камеры и снимать интересные планы сверху, потом сами проявляли и монтировали эту пленку, показывали сюжет в программе молодежного вещания Казахского телевидения. Мы влюбились в этот жанр, и из нашего выпуска несколько человек подались работать именно на ТВ. Мы благодарны своему учителю, который открыл дорогу в тележурналистику.»*

1971 году состоялся очередной выпуск журналистов КазГУ. А перед этим Раиса Мамлютова побывала на преддипломной практике на Сахалине. Работала на радио Южно-Сахалинска, готовя репортажи с рыболовецких траулеров, рыбокомбинатов Курильских островов, рассказывая об исторических памятниках Сахалина. А Затем – Петропавловск. Работа на телевидении захватила ее полностью. *« Семидесятые годы... столько романтики вокруг. Студенческие строительные отряды, участие в фестивалях молодежных программ, дискуссии о современных проблемах, встречи с интересными людьми. А я вспоминаю, как впервые пришла сюда, еще задолго до 12 апреля 1961 года. Мама послала меня за молоком, а его тогда продавали на улице в большой цистерне у магазина. Выстраивалась очередь с битончиками. Вдруг откуда-то голос Левитана: « Говорит Москва! Передаем сообщение ТАСС...». Мы не можем понять, что случилось.... оказалось, что рядом стояла машина и из открытой двери вещало радио. Шло сообщение о том, что в космосе - Юрий Гагарин - первый космонавт Земли! Я схватила свое молоко и, задрав голову в небо, бежала домой, где же он там?*

*Придя, хотела удивить родителей новостью, но они слышали это сообщение, которое прозвучало уже после приземления Гагарина. На утро в школе было столько эмоций, и наша Тамара Георгиевна дала задание просмотреть газеты и на завтра написать сочинение или, кто сможет – стихи на эту тему. Конечно же, я подготовила стих о первом Космонавте. Это было немного наивно, но я стала победителем конкурса юных поэтов Петропавловска и меня пригласили в студию телевидения выступить. Помню, как я громко читала свои стихи в четырнадцать лет, впервые перешагнув порог телестудии. Судьба привела меня сюда. Проработав много лет, я ни разу не сомневалась в правильности выбора. Здесь - вся моя творческая биография!».*

За годы работы Раиса Гарифовна создавала богатейший архив нашего телевидения- «Шанырак»- летопись Независимости, «Истории река», «Отцы и дети», «Из прошлого нашего города», «Репрессии –хроника и жертвы», «Патриот», «Поклонимся великим тем годам», «Земляки» .*«Мне всегда хотелось работать в жанре очерка. «Земляки»- это 38 телевизионных очерков, над которыми я работала в течении 5 лет и старалась увековечить знаменитых северо-казахстанцев, внесших вклад в развитие региона - Магжан Жумабаев, Александр Викторенко, Шамиль Шакшакбаев, Владимир Кардашов, Евгений Тетюхин.... Особенно дорог для меня фронтовой цикл «Поклонимся великим тем годам». Здесь, на Октябрьской площади, когда проводились парады в День Победы, я готовила репортажи вместе со съемочной группой, брала интервью у ветеранов. Помню, как трогательно, иногда со слезами на глазах, они рассказывали о своей военной молодости, о трудностях и победах, о друзьях, не вернувшихся с войны. Я всегда старалась сохранять эти материалы, т.к. тема была близка нам с детства. Мой папа-Мамлютов Гариф Абдуллович прошел с боями до Австрии, Мария Сергеевна Билюкова – наша вторая мама, служила в военно-санитарном поезде на сталинградском фронте. Потом, к юбилею Победы, в 2000 году мы решили провести несколько павильонных передач с участием фронтовиков, женщин и детей войны, работников тыла. А к 60-летию Победы в 2005 году все эти материалы легли в основу двенадцатисерийного документального цикла «Поклонимся Великим тем годам», а затем – и книги с таким же названием. И самое ценное, что работы северо-казахстанцев и на всесоюзных молодежных телефестивалях получали призы. Например, в городе Минске - фильм «Сколько стоит человек» о наших земляках- участниках ядерных испытаний 1954 года, очерк «На родине ССО» о студенческом движении – на фестивале в Баку. Фильм - «Гагаринские строки в биографии» о поездке наших студентов на родину Юрия Алексеевича Гагарина, где мы встретились с его семьей, побывали в доме Гагариных, и я взяла интервью у Анны Тимофеевны - мамы космонавта. Он стал лауреатом республиканского телефестиваля «Жолдас» в Алма-Ате».*

Раиса Гарифовна много лет занималась общественной работой. Почти четверть века она возглавляла областной татаро-башкирский общественный культурный центр «Дуслык». Была членом Ассамблеи народа Казахстана с самых первых лет его создания. *«Наш центр был создан в 1989 году на перестроечной волне – возрождение национальных культур в Казахстане. Уже были общество «Казак теле», корейский центр, русская община «Лад». Мы принимали участие в работе Форума народов Казахстана в 1992 году, когда Н.А.Назарбаев пригласил лидеров национальных объединений, религиозных деятелей, депутатов чтобы посоветоваться о дальнейшей судьбе страны. Именно на этом Форуме в Алма-Ате было принято решение о создании*



***На съезде Всемирного конгресса татар, 2007 год***

*Ассамблеи народа Казахстана. И в марте 1995 года мы, члены Ассамблеи, приняли участие в этом историческом заседании. Это были самые сложные годы и верные шаги, предпринятые нашим Президентом для того, чтобы сохраниться, как многонациональное государство. Все, что мы имеем нынче, было заложено в первые годы независимости. Благодаря Нурсултану Абишевичу Назарбаеву, его восточному видению и философскому пониманию бытия, складывалось будущее страны. Он сумел увидеть перспективу, и мы сегодня входим в число развитых стран мира, нам есть чем гордиться. Новая столица- Астана, построенная с нуля, принимала гостей на «Экспо-2017», в республике проходят международные культурные и спортивные мероприятия, встречи политических деятелей».*

Уйдя на заслуженный отдых, Раиса Гарифовна не сидит сложа руки, она занялась публицистикой и изданием книг. И еще часто бывает со своей семьей, которая живет в Америке. Дочь Альфия, зять Брайн, внучка Даниэль и внук Эрик всегда рады встрече. Они вместе путешествуют, открывая мир и его людей. На этом творческом пути появилась еще одна книга Раисы Гарифовны «Все мы дети земли», в которой автор описывает свои мысли о пройденном, рассказывает о жизни и общих человеческих ценностях .

*«Все мы дети земли», это –своего рода биографический обзор моего прошлого, моих родных, о семье, друзьях и коллегах. Как говорится, за спиной - семь десятков лет и я решила «Оглянуться... и посмотреть повнимательнее....». Начинаешь философствовать, чтобы понять окружающий мир. Работая еще в молодежной редакции, мы объехали почти весь Советский Союз –фестивали, командировки. Потом – побывали в соцстранах на отдыхе. Так складывалось общее представление о мире, в котором мы живем.*

*И вот 10 лет назад я, перелетев океан, оказалась в Америке, в Техасе. Мне было очень интересно увидеть природу, незнакомый образ жизни, людей самых разных национальностей, их быт, культуру, традиции. Долго присматривалась, сравнивала. И я пришла к такой мысли, что все мы живем под одним небом, ходим по одной земле, только надо понимать и ценить то, что имеем. Все люди одинаковые, независимо от цвета кожи, расы, религии. Мы должны твердо знать, что пришли в этот мир не для того, чтобы творить зло и портить природу, а поднять уровень человеческой культуры и мироздания, чтобы дети росли, менялись поколения и были счастливы люди! Да, все мы – Дети Земли!!!»*

***Елена Малюкова, г. Петропавловск***

## ХУШ КИЛДЕҢ, НӘҮРҮЗ БӘЙРӘМЕ!

*Нәүрүз – төрки һәм иран халыкларының кояш календаре буенча яңа ел бәйрәме, яз аеның көн белән төн тигезләшкән көнне билгеләп үтелә. Ул фарсы телендә «яңа көн» дигәнне аңлата. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы хәбәрчесе әлеге бәйрәмнең килеп чыгышын, татар халкына нинди йогынтысы булганын ачыклады, Казахстанның Татар сәнгать мәктәбенең тәрбия эшләре буенча мөдире Диләнур Ахунҗанова белән элемтәгә керде.*

Нәүрүз ислам диненең гореф-гадәтләренә кагылмый, ә бары тик милли традиция булып санала. Нәүрүз бәйрәменең килеп чыгышы безнең эрага кадәр 648-330 елларга ук барып тоташа. Кайбер чыганакларга караганда, Нәүрүз рәсми рәвештә Беренче Фарсы Империясендә бәйрәм ителә башлый (б.э.к. VI – IV гг). Нәүрүз турында фарсы әдәбиятының «Китаплар патшасы» дип йөртелгән дөньядагы иң озын поэма – «Шаһнамә» әсәрендә искә алына. Аның авторы фарсы һәм таҗик шагыйре Фирдәүси Нәүрүзне Җәмшид шаһның патшалык итә башлавыннан бәйрәм ителә дип яза.

Иран мифологиясе буенча, Нәүрүз бәйрәме көнендә Иран патшасы Кей-Кавусның улы Сиявуш җирләнә. Бу легенда шулай ук Фирдәүсинең әсәрендә әйтеп үтелә: «Безгә килеп җиткән чыганакларга күз салсак, Сиявушның гүргә иңдерелгән көне «Нәүрүз» дип аталган, һәм һәр елны бәйрәм буларак билгеләп үтелә...» Нәүрүз бәйрәме көнне иран халыклары үзләренең бабаларының рухларына табына торган була. Бүгенге көндә исә Нәүрүз бәйрәмен күп кенә төрки халыклар билгеләп үтә. Нәүрүз болгарларга һәм башка төрки кавемнәргә иранлылар аркылы мәҗүсилектән кергән дигән фикер йөри

Әлеге бәйрәм язгы яңарыш, уңыш, дуслык, мәхәббәт символы булып санала. Борынгыдан килгән гореф-гадәт буенча, Нәүрүз килер алдыннан кешеләр өйләрен чистартып, хуҗалыкларын тәртипкә китереп, алган бурычларын кире кайтарырга тиеш. Имеш, Нәүрүз чиста йортка, яхшы өй хуҗасына килеп керсә, аны авырулар, уңышсызлыклар читләтеп узган. Ә бәйрәм көн бары тик кич утырулар, кунакка йөрүләр, очрашулар, күңел ачуларга багышлана. Борынгылар фикеренчә, Нәүрүзне шат күңел һәм сый-хөрмәт белән каршы алсаң, ул өйгә муллык һәм ел буена уңыш китерер. Гомумән, бәйрәм хөрмәтеннән халык агачлар, чәчәкләр утырткан.

Нәүрүз бәйрәме 2009 елда ЮНЕСКО тарафыннан Бөтендөнья матди булмаган мәдәни мирас исемлегенә кертелә, 2010 елгы БМОның Генераль Ассамблеясе карары нигезендә Халыкара бәйрәм статусын ала.

Казахстанда Нәүрүз ничек бәйрәм ителә?

Диләнур Ахунҗанова сүзләренә караганда, Нәүрүз Казахстанның Семей шәһәрендә 14 мартта старт алган. «Нәүрүз – үзенчәлекле бәйрәм. Ул символик мәгънәләргә бай,-ди Диләнур Ахунҗанова. - Мәсәлән, һәр кеше җиде ишекне ачып, җиде йортка керергә тиеш. Алар йортның хуҗаларына сәлам әйтә, хәлләрен сорашып, бәйрәм белән котлый. Һәр кеше казанда кайнап торган нәүрүз күҗен татып карарга тиеш. Нәүрүз күҗе – аш дигәнне аңлата, ул җиде ингредиенттан тора: ит, он, тоз, сөт, май һәм җиде төрле ярма (дөге, солы, карабодай, кукуруз, тары, бодай, арпа). Һәрбер компонент үзенә күрә бер мәгънәгә ия: муллык, бәхет, табигатьнең яңарышы һ.б. Шулай ук Нәүрүз бәйрәмендә табынга бавырсак, кымыз, казы-карта (ат итеннән ясалган ысланган казылык), шелпек (лавашка охшаган камыр ризыгы), җәя (сарык итенең бер өлеше) куела.

Нәүрүз бәйрәме көнне һәр кеше кунак кабул итә, махсус милли киемнәр киелә. Өйләрне тәртипкә китергәч, барысы да




мәйданнарга чыгып бәйрәм итә. Гадәттә, мәйданнарда казахларның тарихи юрталары куела. Шул юрталарда зур оешмалар өстәл әзерли һәм барлык теләгән кеше дә милли ризыкларны авыз итеп карый ала. Зурлатып концерт уздырыла: җор телле кешеләр – акыннар – үзләренең тапкыр сүзләре белән тамашачыларны таң калдыра, җырлый, шигырьләрен сөйли, милли уен коралларында уйный. Яшьләр исә, алтыбакан дигән таганда атына. Алтыбакан – кояш һәм айның гармониясен белдерә. Төрле бәйге-көрәшләр үтә, тугыз комалак дигән мантыйк уеннары оештырыла. Нәүрүз бәйрәменең Казахстанда тагын бер үзенчәлеге бар: бәйрәм көннәрендә дәүләт оешмалары хезмәткәрләре милли киемнәр киергә тиеш.

Нәүрүз бәйрәмен казахлар гына бәйрәм итә димәс идем, Казахстанда яшәүче барлык милләтләр дә катнаша. Гадәттә, татар сәнгать мәктәбендә дә уздырыла. Казахлар да, татарлар да милли ризыкларын алып килеп бәйрәм итә. Казахстанда көн дә бәйрәм, көн дә туй! Шуңа күрә казахлар татар бәйрәмнәрендә, ә татарлар казах бәйрәмнәрендә катнаша».

Нәүрүзне татар халкы бәйрәм иткәнме?

Нәүрүзнең татарларда зурлап үткәрелгән бәйрәм буларак билгеле булуына ишарә итүче чыганак хезмәтләр бар. Әйтик, күренекле татар тарихчысы, мәгрифәтче Шиһабетдин Мәрҗәнинең XIX гасырда иҗат иткән хезмәтләренә караганда, 1700 елга кадәр мөселман татарлары яңа елны фарсы кояшы елы буенча хәмәл (март) аенда көн һәм төн озынлыгы тигезләшкән вакытта башлаган. Тарихчы беркадәр Нәүрүз бәйрәменә бәйле кайбер сәхифәләр дә китерә : «Муса мелла (Муса Түнтәри) заманында нәүрүз әйтеп йөрү булган. Март башларында тирән чана әзерләп, аның уртасына карья мелласы кереп утырып, аны кырык – илле кеше җигелеп тартып, авылның бер башыннан икенче башына нәүрүз әйтеп, мелла файдасына ашлык җыеп йөргәннәр».

Филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов Шиһабетдин Мәрҗанинең XVIII йөзгә караган кульязма хезмәтләрендә яз айларын татарларда өч өлешкә бүлеп, «бала нәүрүз, карт нәүрүз, эсселек нәүрүзе» дип йөртелүе турында мәгълүматлар барлыгын искәртә. Шулай ук, Марсель Әхмәтҗанов Нәүрүз бәйрәмен XVII йөзгә үк караган кулъязма китапта урын алган «Илаһи мөнәҗәт» әсәре текстында табуын әйтә. Ул бу текстның татар әдәбиятының күренекле вәкиле Мәүлә Колыйның «Хикмәте хәким» шигыренең варианты булын искәртә. Автор билгеләвенчә, әлеге әсәр: «Булса Нәүрүз көнләри, күңле йыглар уганга. Йирдинйә шуд чыгу бән Санә әйтер Сөбханга» юллары белән башланып китә.

Күренгәнчә, татарларда соңгы берничә гасыр аралыгында Нәүрүз бәйрәме зурлап үткәргән бәйрәм саналмаса да, әлеге бәйрәмнең тарихи җирлеге бар һәм ул татар халкы мәдәни традициясенә мөнәсәбәтле дигән фикерне ассызыклый алабыз.

***Зилә Мөбәрәкшина***

***Фото:Диләнур Ахунҗанова***




ҚҰРМЕТТІ СЕМЕЙЛІКТЕР МЕРЕКЕ ҚҰТТЫ БОЛСЫН!
РУХАНИ
ЖАҢҒЫРУ



## ДЕНЬ БЛАГОДАРНОСТИ

В День Благодарности актив Татарского культурного центра Западно-Казахстанской области начал с посещения Западно-Каахстанского гуманитарного института. Поздравили студентов сирот, студентов из малообеспеченных семей, студентов из незащищенных слоев населения, вручив им продуктовые пакеты от председателя правления Миликеевой Ф.И.

На другой день приняли участие в митинге у монумента «Қазақ халқына мың алғыс», посвященном празднованию Дня Благодарности, с участием заместителя акима области Г.А. Оспанкулова, где члены АНК возложили цветы к монументу.

Активист культурного центра Хузасаитов З.К. посетил встречу с уважаемыми старейшинами области с участием акима области А.С. Кульгинова в Доме АНК ЗКО.

После чего в зале «Ақжайық» акимата области прошла республиканская интерактивная видеоконференция, посвященная Дню Благодарности, с участием акима области А.С. Кульгинова и государственного секретаря РК Г.Н. Абдыкаликовой на которой также присутствовал актив культурного центра.

А так же в День Благодарности офис центра и музей Г. Тукая посетил сопредседатель Совета муфтиев России, муфтий Саратовской области Бибарсов Мукаддас Аббасович, который с большим удовольствием выслушал экскурсию и оставил свои впечатления в книге почетных посетителей музея, а также поделился своими впечатлениями на своей страничке в соц. сетях.

***Флюра Миликеева, г.Уральск***

*Казакъстан татарлары һәм башкортлары Конгрессы оешмаларының иҗтимагый- мәдәни тормышы фотографияләрдә*















==================================================================

***Дорогие читатели газеты!***

***Ваши материалы для помещения в газете следует отправлять по электронной почте в адрес [griftim@mail.ru](mailto:griftim@mail.ru).***

***Напоминаем, что редакция не рецензирует материалы, а также не выражает публично свое отношение к содержанию и форме представленных материалов.***



| | |
|---|---|
| Главныйредактор<br>Г.Т.Хайруллин<br>Компьютерная верстка<br>Р.Р.Наратов | Свидетельство о постановке на учет средств массовой информации<br>№13715 от 26 июня 2013 года. Выдано Комитетом архивов Министерства культуры и информации РК |